КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 17 гыйнвар г.Казань № 17

Агросәнәгать комплексына дәүләт
ярдәме күрсәтү чаралары турында

Тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013-2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәлә) расларга:

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге, ачык грунт яшелчәләре һәм озын сүсле җитен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә затлы орлыкчылыкны үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә күпьеллык үсентеләр үстерүдә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сөтле терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән, Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә нәселле терлекчелеккә булышлык күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сарык һәм кәҗәләрнең ана башларын саклау һәм үрчетү чыгымнарының бер өлешен каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә агросәнәгать комплексы объектларын төзү һәм модернизацияләүгә турыдан-туры тотылган чыгымнарның бер өлешен каплау өчен, шулай ук техника һәм җиһазлар сатып алу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә культуртехника, урман агромелиорациясе һәм гидромелиорация чараларын үткәрүгә бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Агросәнәгать комплексында инвестиция кредитлары (заемнары) буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Озак вакытлы, уртача вакытлы һәм кыска вакытлы кредитлар буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы иминиятләве шартнамәләре буенча иминият премияләрен түләү өчен чыгымнарның бер өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибен;

Эшләрен башлап җибәрүче фермерларга дәүләт ярдәме күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибен;

Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибен;

Авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган грантлар бирү тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына конкурс нигезендә эшли генә башлаган фермерларга дәүләт ярдәме күрсәтүгә, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә, авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерүгә әлеге максатларга тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган акча исәбеннән бирелә торган грантларны гамәлгә куючы булырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин